СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2021 г. Заинск № 64

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2016 елның 04 февралендәге 35 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 04 декабрендәге 201-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2016 елның 4 февралендәге 35 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1.2, 5.1.4, 5.1.5, 5.2.6, 5.3.4, 5.6.2, 5.7.6 пунктларда «СП 42.13330.2011» сүләрен «СП 42.13330.2016» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 6.2 пунктта:

- «СП 42.13330.2011» сүзләрен «СП 42.13330.2016» сүзләренә алмаштырырга,
- «СанПиН 42-128-4690-88» сүзләрен «СанПиН 2.1.3684-21» сүзләренә алмаштырырга,
- «СанПиН 2.1.1279-03 «Зиратларны, җирләү билгеләнешендәге бина һәм корылмаларны урнаштыру, төзү һәм карап тотуга гигиена таләпләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Әгъләмов Р.В.).

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**